СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**« 14 » декабрь 2022 ел** **№ 177**

**2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында» Арча район Советының 2016 елның 16 августындагы 71 номерлы карарына (11.12.2019 ел, №299 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2016 елның 16 мартындагы 12 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Район Советы **карар бирде**:

1. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында» Арча район Советының 2016 елның 16 августындагы 71 номерлы карарына (11.12.2019 ел, №299 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының икътисади үсеш, авыл хуҗалыгы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
14 декабрь 2022 ел, №177
карарына кушымта

# 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеш СТРАТЕГИЯСЕ

Арча шәһәре, 2022 ел

## ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| | 2016-2019 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясе паспорты | 3 |
| 1 | Гомуми нигезләмәләр | 5 |
| 2 | АМР стратегиясенең максатлары һәм бурычлары | 6 |
| 3 | АМР социаль-икътисади хәленә характеристика | 6 |
| 3.1 | Икътисади-географик урынның төп белешмәләре һәм үзенчәлекләре | 6 |
| 3.2 | Төп социаль - икътисади күрсәткечләр | 8 |
| 4 | АМР ның конкурентлык өстенлекләре | 13 |
| 4.1. | Транспорт-логистика инфраструктурасы | 13 |
| 4.2 | Хезмәт базары | 14 |
| 4.3 | Инвестиция эшчәнлеге | 14 |
| 5 | Социаль-икътисади үсешнең институциональ факторлары | 14 |
| 5.1 | Институциональ факторлар кысаларында проблемалар үзенчәлеге | 16 |
| 5.1.1 | Икътисади бөтенлек | 16 |
| 5.1.2 | Инвестицион җәлеп итүчәнлек. Эшлекле активлык | 22 |
| 5.1.3 | Кеше капиталы һәм хезмәт базары. Шәһәрләшү (урбанизация) | 27 |
| 5.1.4 | Дәүләт һәм муниципаль идарә | 31 |
| 6 | АМР стратегиясен гамәлгә ашыру сроклары | 46 |
| 7 | АМР стратегиясен гамәлгә ашыру механизмы | 47 |
| 8 | АМР стратегиясен гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү | 49 |
| 9 | Арча муниципаль районында гамәлгә ашырыла һәм үсеш стратегиясендә кулланыла торган муниципаль программалар исемлеге | 49 |
| | Арча муниципаль районының 2030 елга кадәрге фараз күрсәткечләре | 51 |
| | 2030 елга кадәр Арча муниципаль районы бюджетының фаразланган керемнәре һәм чыгымнары | 55 |

**2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорга Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясе паспорты**

| | |
|---|---|
| Стратегияне җаваплы башкаручы | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Стратегияне башкаручылар | Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары |
| Стратегиянең максатлары | Муниципальара кооперация элемтәләрен үстерү, инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру һәм югары җитештерүчән эш урыннары булдыру нигезендә Арча муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын күтәрү |
| Стратегиянең бурычлары | 1) уңай инвестицион климат булдыру;<br>2) югары җитештерүчән эш урыннары булдыру;<br>3) кеше капиталын торгызу һәм үстерү өчен шартлар тудыру;<br>4) төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү;<br>5) социомәдәни хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү һәм алар белән норматив тәэмин ителешкә ирешү;<br>6) ял итү һәм эшләү өчен уңайлы территорияләр булдыру;<br>7) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>8) нәтиҗәле муниципальара хезмәттәшлек системасын булдыру;<br>9) Арча муниципаль районының финанс-икътисади бөтенлеге дәрәҗәсен күтәрү. |
| 2030 елга стратегияне гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре | - тулай территориаль продукт үсеше 2016 елга 2,5 мәртәбә артачак;<br>- хезмәт җитештерүчәнлеге 65% дәрәҗәсендә булачак;<br>- 2016 елга АМРда хезмәт хакы 2,3 мәртәбә артачак;<br>- социаль өлкә хезмәтләре белән тәэмин ителеш норматив дәрәҗәдән ким булмаячак;<br>- гомер озынлыгын 75 яшькә кадәр җиткерү;<br>- социаль өлкә хезмәтләре белән тәэмин ителеш норматив дәрәҗәдән түбән дәрәҗәдә түгел.<br>Стратегия Арча муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге үсеше перспективасы буенча эшләнде |
| Стратегияне финанслау* | РФ бюджеты<br>ТР бюджеты<br>Җирле бюджет 100,0 мең сум<br>Бюджеттан тыш чыганаклар 5 600 000,0 мең сум<br>*финанслау күләме ел саен җирле бюджетны формалаштырганда һәм кабул иткәндә билгеләнә (җирле бюджеттан финанслашу белән бәйле чаралар өчен).<br>Финанслау күләме республика бюджеты акчалары |

| | |
|---|---|
| | исәбеннән бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштыру этабында билгеләнә һәм Татарстан Республикасы бюджетын кабул итү процессында төзәтмәләр кертелә. |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеше стратегиясе (алга таба – Стратегия) «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба Стратегия – 2030) төп нигезләмәләре нигезендә эшләнде.

Арча муниципаль районы (алга таба - АМР) стратегиясен гамәлгә ашыруның төп максаты - муниципальара кооперация элементләрен үстерү, инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру һәм югары җитештерүчән эш урыннары булдыру нигезендә Арча муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын яхшырту.

АМР Стратегиясен гамәлгә ашыру чоры югарыда телгә алынган законнар нигезендә башкарыла.

АМР Стратегиясен эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Стратегия -2030 да билгеләнгән диапазонда өч еллык планлаштыру методын -3,6 һәм башка еллар-куллану планлаштырыла.

Стратегиянең беренче этабын гамәлгә ашыру (2016-2018 еллар) икътисади кризис һәм Россия икътисады кимү шартларында, халыкара санкцияләр саклану нәтиҗәсендә, нефтьнең бәясе түбән булуы, шулай ук икътисади хәлнең начараюы сәбәпле, максатчан күрсәткечләргә ирешмәү куркынычы белән бәйле.

Икенче этап (2019-2021 еллар) конкуренциягә сәләтлелекне үстерү, АМР икътисады потенциалын ачу өчен шартлар тудыру модельләренә нигезләнгән.

Өченче этап (2022-2024 еллар) - кластерлы активлаштыру, икътисадның конкуренциягә сәләтлелеген арттыру, үсешнең яңа балансланган моделенә, кеше потенциалының һәм социаль киңлекнең сыйфатын сизелерлек яхшыртуга, «заманча икътисад» структура модернизациясен тирәнәйтүгә, яңа «акыллы икътисад»ны үстерүгә, инновацияләрне икътисади үсешнең әйдәп баручы факторына әверелдерүгә нигезләнеп район икътисадының конкуренциягә сәләтлелеген арттыру.

Дүртенче этап (2025-2030 еллар һәм аннан соң) — Арча муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсеше, кайбер төп юнәлешләр кысаларында конкуренциягә сәләтлелеккә ирешү һәм алга таба үсеш өчен шартлар тудыру.

Чаралар планын үтәү нәтиҗәләре буенча һәм АМР үсешенең тышкы һәм эчке факторларыннан чыгып, ел саен чираттагы өч еллык план чорына чаралар җентекләп анализлана. 2021 елда, АМР стратегиясенең чираттагы этабы тәмамлангач, кирәк булганда, аңа тиешле үзгәрешләр кертелә, шулай ук чираттагы алты елга чаралар планы эшләнә.

АМРның социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен хәл итү үсешкә комачаулый торган проблемалар исемлегенә һәм сәбәп-нәтиҗә элементләренә нигезләнә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы премьер-министры И.Ш. Халиков һәм муниципаль берәмлекләр Советы Президиумы рәисе М.З. Шакиров тарафыннан расланган Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының (алга таба – ДХБО) һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының (алга таба-ҖҮО) уртак чаралар планы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең 03.03.2016 ел, № 01-2264 съезды йомгаклары буенча АМР авыл җирлекләре АМР стратегиясе кысаларында үзләренең социаль-икътисади үсеш планнарын эшлиләр. Аларның үтәлешен мониторинглауны АМР Башкарма комитеты (алга таба -АМР БК) тәэмин итә.

Мониторинглау тәртибе, аның нәтиҗәләрен куллану "Стратегияне гамәлгә ашыру механизмы" исемле 7 бүлектә тасвирланды.

## 2. АМР Стратегиясенең максатлары һәм бурычлары

АМР Стратегиясен гамәлгә ашыруның максаты инвестицион җәлеп итүчәнлекне, кеше капиталын үстерү һәм тулай территориаль продуктны арттыру нигезендә Арча муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын яхшырту.

Бу максатка ирешүне тәэмин итү өчен чаралар берүк вакытта өч юнәлештә башкарылырга тиеш: кеше потенциалын үстерү, территорияне үстерү һәм икътисадны үстерү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру
2. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү
3. Агросәнәгать комплексын үстерү
4. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү
5. Финанс-икътисади бөтенлек дәрәҗәсен арттыру
6. Яңа эш урыннары булдыру
7. Сәламәтлекне саклау һәм озын гомерлелек
8. Яшәү өчен уңайлы мохит булдыру
9. Туризмны үстерү
10. Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру
11. Социаль-мәдәни хезмәтләрнең сыйфатын арттыру һәм алар белән тәэмин ителеш нормасына ирешү

## 3. АМРның социаль-икътисади торышына характеристика

### 3.1. Икътисади-географик урыны турында төп мәгълүмат һәм үзенчәлекләре

Арча муниципаль районы - Татарстан Республикасының көнбатышында, Кама аръягының төньяк өлеше үзәгендә урнашкан иң эре районнарының берсе, ул 1930 елда төзелгән.

Административ үзәге - Арча шәһәре - Казансу елгасы ярында, Татарстан башкаласыннан 60 чакрым ераклыкта, Казан-Ижау линиясендәге тимер юл станциясе, Казан-Киров автомобиль юлы төенендә урнашкан.

Риваять буенча, Арчага Батый хан XIII гасырда нигез салган. 1552 елда Иван Грозный указы белән Арчага укчылар воеводасы җибәрелә, 1606 елда Арча

ныгытмага әйләнә. 1781 елда Арча өяз шәһәре төзелә. 1926 елдан - авыл җирлеге, 1938 елдан - шәһәр тибындагы бистә, 2008 елның 24 июнендә шәһәр статусы бирелә.

АМРның территориясе 1843 кв.км (Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 2,72 %ы) 49,8 мең кеше яши (1 нче таблица) (Татарстан Республикасы халкының гомуми санының 1,28 % ы). Арча шәһәрендә 22,5 мең кеше (район халкының гомуми санының 45,2 %), авыл җирлегендә 27,3 мең кеше (54,8 %) яши. Халыкның тыгызлыгы 1 кв. километрга 27 кеше.

Районда түбәндәге милләтләр яши: татарлар (92,8 %), руслар (5,9 %), башка милләтләр (1,3 %).

Районда 1 шәһәр һәм 16 авыл җирлеге, барлыгы 128 торак пункт бар (2 нче таблица).

1 нче таблица. АМР да халык саны динамикасы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ел башына халык саны, шул исәптән яшь буенча: | мең кеше | 52,53 | 52,62 | 52,27 | 51,83 | 51,29 | 50,58 |
| - Эшкә яраклы яшьтән кечерәк | % | 19,5 | 19,4 | 19,4 | 19,4 | 19,3 | 19,4 |
| - Эшкә сәләтле яшьтә | % | 57,5 | 57,2 | 56,8 | 56,2 | 57,1 | 56,6 |
| - Эшкә яраклы яшьтән зуррак | % | 23,0 | 23,4 | 23,8 | 24,4 | 23,6 | 24,0 |
| Ир-атлар саны | мең кеше | 25,04 | 25,11 | 24,94 | 24,81 | 24,61 | 24,28 |
| Хатын-кызлар саны | мең кеше | 27,49 | 27,51 | 27,33 | 27,02 | 26,68 | 26,30 |

2 нче таблица. 01.01.2022 елга АМР авыл җирлекләре

| № | Җирлек исеме | Административ үзәк | Торак пунктлар саны | Халык саны (кеше) |
|---|---|---|---|---|
| | Шәһәр җирлеге: | | | |
| 1 | Арча шәһәре | Арча шәһәре | 4 | 22 512 |
| | Авыл җирлекләре: | | | |
| 1 | Апаз | Апаз авылы | 6 | 1 746 |
| 2 | Кәче | Кәче авылы | 5 | 1 026 |
| 3 | Наласа | Наласа авылы | 3 | 841 |

| № | Җирлек исеме | Административ үзәк | Торак пунктлар саны | Халык саны (кеше) |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Яңа Кенәр | Яңа Кенәр авылы | 11 | 4 035 |
| 5 | Яңа Кишет | Яңа Кишет авылы | 4 | 917 |
| 6 | Яңа Кырлай | Яңа Кырлай авылы | 8 | 1 723 |
| 7 | Сеҗе | Курса-Почмак авылы | 15 | 2 702 |
| 8 | Урта Аты | Түбән Аты авылы | 5 | 952 |
| 9 | Урта Курса | Урта Курса авылы | 7 | 992 |
| 10 | Иске Кырлай | Түбән Мәтәскә авылы | 9 | 2 048 |
| 11 | Иске Чүриле | Иске Чүриле авылы | 10 | 1 362 |
| 12 | Ташкичү | Ашытбаш авылы | 7 | 2 368 |
| 13 | Үрнәк | Үрнәк бистәсе | 16 | 2 996 |
| 14 | Утар -Аты | Утар -Аты авылы | 6 | 1 118 |
| 15 | Шушмабаш | Шушмабаш авылы | 10 | 2 042 |
| 16 | Яңасала | Яңасала авылы | 2 | 418 |

### 3.2. АМР ның төп социаль-икътисади күрсәткечләре

АМР Стратегиясенең халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән максатларына нигезләнеп, аны гамәлгә ашыруның төп чаралары икътисади үсеш темпларын күтәрүгә, инвестицияләр җәлеп итүгә, социаль инфраструктураны үстерүгә, мәгарифнең, сәламәтлек саклауның, торакның һәркем алырлык булуын һәм сыйфатын арттыруга, экологик иминлекне үстерүгә юнәлдерелгән.

2021 ел нәтиҗәләре буенча, тулай территориаль продукт күләме 14 325,6 млн. сум тәшкил итте. 1 нче рәсемдә АМР икътисадының гомуми структурасы тәкъдим ителде.

1 нче рәсем. Тулай территориаль продукт структурасы, %




Бүген АМР икътисадының төп юнәлеше - авыл хуҗалыгы җитештерүе. Авыл хуҗалыгы җитештерүе - терлекчелек һәм үсемлекчелек.

АМР территориясендә «АК Барс» ХК ААҖ, «АРЧА» ҖЧҖ, «Сервис Агро» ҖЧҖ һәм 60 КФХ кебек эре инвесторлар катнашында 17 авыл хуҗалыгы оешмасы эшчәнлек алып бара. Барлык категория хуҗалыклар буенча авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләрнең уртача саны 2022 елның 1 гыйнварына 1870 кешегә җитте.

АМР авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре энергияне сак тоту технологияләрен гамәлгә кертү буенча эш алып бара. Бу максатларда машина-трактор паркын заманча, техник яктан камилләштерелгән машиналар белән яңарту бара. Бүгенге көндә АМРда 24 югары җитештерүчән чәчү комплексы, 34 Нью Холланд, Клаас Лексион маркалы чит ил ашлык җыю комбайны эшли. 100 га чәчүлек җирләренең энергия белән тәэмин ителеше 178 ат көче тәшкил итә (Татарстан Республикасы буенча-176 ат көче). Энергияне саклый торган технологияләр чәчү мәйданнарының 95%тан артыграгында кулланыла, бу туфракның уңдырышлылыгына йогынты ясый торган биологик факторларның әһәмиятен арттырырга мөмкинлек бирде. Перспективалы сортлар кертелә. Гомумән алганда, үсемлекчелектә уңай динамика күзәтелә.

Терлекчелек өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешү өчен югары продукция бирә торган нәселле терлекләр белән яңарту буенча эш алып барыла. Соңгы елларда АМР буенча терлекчелек биналары реконструкцияләнде, сөтчелек комплекслары төзелде, бу сөт җитештерү күләмен арттыруга ирешергә ярдәм итте.

Гомумән алганда, АМР тулай территориаль продуктында агросәнәгать комплексы (алга таба - АПК) секторы 44,3 % тәшкил итә.

Район сәнәгатен азык-төлек, җиңел сәнәгать һәм төзелеш материаллары җитештерү тәшкил итә. Районның сәнәгать җитештерүе структурасында 72,5%ны азык-төлек сәнәгате алып тора, 23,9%ы - төзелеш материаллары җитештерүе, 3,6%ы - җиңел сәнәгать.

Дәүләт урман фондын саклау һәм торгызу мәсьәләләре белән «Арча урманчылыгы» ДКУ шөгыльләнә.

АМР территориясендә торак-коммуналь хезмәтләрне «Жилкомбытсервис» ҖЧҖ, «Водоканал-Сервис» ҖЧҖ һәм «Тепло-Сервис» ҖЧҖ күрсәтә. Торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән индекслар чикләрендә расланды.

Торак йортлар төзелешенә бирелгән рөхсәтләр нигезендә каралган торак төзелеше күләме 2022 елның 9 аенда торак урыннарның гомуми мәйданы буенча 28845 кв. метр тәшкил итте.

Республиканың эре районнарыннан берсе буларак, АМР гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәренә ия. Гомуми файдаланудагы, федераль һәм төбәк әһәмиятендәге юлларның озынлыгы 01.01.2022 елга 438 км тәшкил итә.

Коммуникация һәм биллинг хезмәтләре базарында Арча ЗУЭС предприятиесе эшли. Район эчендәге телефон элемтәсе цифрлы телефон станцияләре ярдәмендә тәэмин ителә. АМРда мобиль элемтәне Билайн, МТС, Мегафон, Летай һәм башкалар тәэмин итә. Почта элемтәсе хезмәтләрен «Россия почтасы» күрсәтә.

Банк эшчәнлеген район территориясендә Саклык банкы ГАҖ, «Ак Барс» Банк» ГАҖ, «Россельхозбанк» АҖ башкара.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәтләрне «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, 2 табиб амбулаториясе һәм 53 ФАП, шул исәптән 13 модульле ФАП күрсәтә. Тәүлек буе койкалар белән тәэмин ителеш 10 мең кешегә 48,8, табиблар белән тәэмин ителеш 10 мең кешегә 15,5, урта медицина хезмәткәрләре белән- 78,1 берәмлек тәшкил итә. Табибларның яртысыннан артыгы югары категориягә ия. АМР Татарстанның төньяк-көнбатыш төбәгендә сәламәтлек саклау системасының төп базасы булып санала. Нәкъ менә Арча үзәк хастаханәсе базасында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан инсульт авырулары өчен йөрәк-кан тамырлары үзәге эшли. Аңа 196 мең халкы булган 7 район беркетелгән, шулай ук икенче дәрәҗәдәге травматология үзәге дә эшли, ул шулай ук республиканың бөтен төньяк-көнбатышына хезмәт күрсәтә. Арча үзәк хастаханәсе базасында беренчел онкология кабинеты эшли.

Арча районында 15 урта мәктәп, 17 төп гомуми белем бирү мәктәбе, 2 башлангыч мәктәп бар, укучылар саны 5 338 кеше, 55 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 48 мәктәпкәчә учреждение эшли, аларда 2 371 бала тәрбияләнә, Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте, 77 нче һөнәр лицее бар.

Өстәмә белем бирүче 2 учреждение - «Арча укучылар сарае» һәм «Яңа Кенәр балалар иҗат йорты», «Арча» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе һәм «Арча Арена» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли.

Мәдәният тармагын 76 клуб учреждениесе, 57 китапханә, балалар сәнгать мәктәбе, район мәдәният йорты һәм «Казан арты» тарих-этнография музее тәшкил итә.

АМРда халыкның төрле категорияләренә социаль ярдәмне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бүлеге башкара.

2018-2021 елларда АМРның социаль-икътисади үсеше түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана (3 нче таблица).

3 нче таблица. 2021-2022 елларда АМР социаль-икътисади үсеше күрсәткечләре динамикасын бәяләү

| Күрсәткеч исеме | 2021 гыйнвар-декабрь | | 2021 гыйнвар-август | | 2022 гыйнвар-август | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | район | ТР | район | ТР | район | ТР |
| Типик гаилә әгъзасына айлык уртача хезмәт хакының һәм минималь куллану бюджетының нисбәте, тапкыр | 2,07 | 2,32 | 1,70 | 2,40 | 1,69 | 2,34 |
| Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе, % | 0,44 | 0,56 | 0,85 | 0,86 | 0,39 | 0,51 |
| Бер кешегә өстәмә бәя, мең сум | 25,04 | 356,56 | 18,42 | 232,36 | 21,79 | 325,01 |
| Өстәлгән бәя *, млн. сум | 1 267 | 1 388 480 | 932 | 904 846 | 1 085 | 1 263 125 |
| Төп капиталга инвестицияләр (бюджет акчаларыннан тыш) җан башына тулы әйләнеш буенча, мең сум | 55,96 | 103,98 | 11,93 | 25,70 | 15,23 | 29,42 |
| Төп капиталга инвестицияләр (бюджет акчаларыннан тыш) тулы әйләнеш буенча, млн сум | 2 830 | 404 915 | 603,58 | 100 082 | 758 | 114 333 |
| Бер кешегә исәпләгәндә файдалануга тапшырылган торак йортларның гомуми мәйданы, кв.м. | 0,49 | 0,77 | 0,35 | 0,49 | 0,48 | 0,64 |
| Гамәлгә кертелгән торак йортларның гомуми мәйданы, кв метр. | 25 022 | 3 011 451 | 17 804 | 1 896 726 | 23 842 | 2 492 610 |
| Бер кешегә салым һәм салым булмаган керемнәр, мең сум | 10,40 | 14,35 | 4,76 | 6,13 | 4,95 | 6,64 |
| Салым һәм салым булмаган керемнәр, млн сум | 525,94 | 55 890,85 | 240,64 | 23 858,76 | 246,25 | 25 793,72 |
| Җан башына икътисади эшчәнлекнең чиста төрләре буенча | 36,54 | 1 028,70 | 19,28 | 634,82 | 48,60 | 779,33 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| җибәрелгән үзебез җитештергән товарлар, мең сум | | | | | | |
| Икътисади эшчәнлекнең чиста төрләре буенча җибәрелгән үзебез җитештергән товарлар, млн. сум | 1 849 | 4 005 900 | 975 | 2 472 083 | 2 420 | 3 028 801 |
| Авыл хуҗалыгында бер эшләүчегә авыл хуҗалыгының җыелма продукциясе, мең сум | 2 924 | 3 273,70 | 305,11 | 484,89 | 441,70 | 623,10 |
| Авыл хуҗалыгының җыелма продукциясе (авыл хуҗалыгы оешмалары буенча), млн. сум | 5 450 | 162 855 | 6230,3 | 23 152,23 | 7543,9 | 27 846,53 |

2018-2022 елларда төп макроикътисади күрсәткечләр буенча АМР икътисады үсеше динамикасын анализлау 4 таблицада тәкъдим ителде.

**Район икътисадының төп күрсәткечләре**

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы буенча тулай территориаль продукт күләме | Млрд. сум | 2622,8 | 2808,8 | 2633,9 | 3354,9 | - |
| Районның ТТП күләме | Млрд. сум | 12,3 | 13,7 | 13,9 | 14,3 | - |
| ТРда ранг | Урын | 26 | 26 | 26 | 28 | |
| Өстәлгән бәя күләме | Млн сум | 1 605 | 1 989 | 2 184 | 1 710 | 1 085январь-июнь |
| Узган елның шушы чорына сәнәгать җитештерүе индексы | % | 76,3 | 68,1 | 108,4 | 88,7 | 146,7гыйнвар-август |
| ТР буенча узган елның шушы чорына сәнәгать җитештерүе индексы | % | 102,6 | 102,4 | 96,6 | 108,9 | 109,3гыйнвар-август |
| ТРда ранг | Урын | 43 | 44 | 8 | 41 | 1гыйнвар-август |

АМР халкының тормыш дәрәҗәсе динамикасын характерлаучы төп күрсәткечләр 5 нче таблицада күрсәтелде.

**Халыкның тормыш дәрәҗәсе**

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Тормыш дәрәҗәсе | бер. | 1,42 | 1,43 | 1,33 | 1,33 | |
| Җан башына акчалата керем | сум | 17446,5 | 18853,1 | 18878,9 | 20437,9 | 21109,50 гыйнвар-июнь |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 23 233,6 | 24 407,6 | 29 349,0 | 29 931,8 | 35 956,6гыйнвар-июль |
| ТР буенча уртача айлык хезмәт хакы | сум | 35 172,2 | 37 418,3 | 39 588,3 | 45 800,3 | 49 942,6гыйнвар--июль |
| Айлык уртача исәпләнгән хезмәт хакының үсеш темплары | % | 109,7 | 105,1 | 108,3 | 110,8 | 115,4гыйнвар--июль |
| Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе | % | 0,47 | 0,50 | 1,16 | 0,44 | 1 октябрьгә 0,35 |
| ТР буенча теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе | % | 0,50 | 0,54 | 1,90 | 0,56 | 1 октябрьгә 0,49 1 |
| Эшсез статусына ия гражданнар саны (мәшгульлек хезмәтендә исәптә торучы эшсез гражданнардан) | кеше | 120 | 128 | 295 | 112 | 1 октябрьгә 88,00 |

3-5 нче таблицаларда күренгәнчә, АМР социаль-икътисади үсешенең төп күрсәткечләренең үсеш темплары уртача республика күрсәткечләреннән артыграк. Җибәрелгән товар күләме 2,5 тапкырга артык, сәнәгать җитештерүе индексы 146%, республика үсешендә 109%, тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе чагыштырма бәяләрдә 122%ка артык. Хезмәт хакы үсеше 115,4 % тәшкил итте, бу республика буенча күрсәткечтән югарырак (109 %). Республика күрсәткече 0,49% булган эшсезлек дәрәҗәсе 0,35% тәшкил итте.

## 4. АМР ның конкурентлык өстенлекләре
### 4.1.Транспорт-логистика инфраструктурасы

АМР Татарстан Республикасының төньяк-көнбатышында отышлы икътисади-географик урынны алып тора, республика башкаласын Киров өлкәсе, Удмурт Республикасы һәм Пермь өлкәсе белән тоташтыручы транспорт магистральләрендә булганга, ресурслар белән җитәрлек тәэмин ителә (файдалы казылмалар, урман, су, җир ресурслары).

АМР Казан шәһәренә транспорт белән бер сәгатьтә барып җитү мөмкинлегенә ия. АМР территориясе үзләштерелү дәрәҗәдәсе буенча уртача үзләштерелгән территорияләргә керә (АМР территориаль планлаштыру схемасы мәгълүматлары буенча). Халыкның уртача тыгызлыгы - 1 кв. км га 27,8 кеше (уртача республика күрсәткече - 1 кв. км га 55,7 кеше).

АМР төньякта Марий Эл Республикасы һәм Татарстан Республикасының алты муниципаль районы белән чиктәш:

көнбатышта - Әтнә һәм Биектау муниципаль районнары белән;

көнчыгышта - Балтач һәм Саба муниципаль районнары белән;

көньякта - Теләче һәм Питрәч муниципаль районнары белән.

АМР территориясе нигездә елга үзәннәре белән киң, сөзәк кишәрлекләргә бүлгәләнгән калкулыклы тигезлекләрдән тора. Төньякта рельефта Нократ Увалларының тармаклары яхшы күренә. Татарстан Республикасы составында АМР Идел буе федераль округына, Европа макроикътисади зонасына һәм Идел буе икътисади районына керә.

АМР территориясе аша магистраль газүткәргечләр һәм нефть үткәргечләр системасы, йөк һәм пассажирлар агымын Россия Федерациясе төбәкләренә һәм Татарстан Республикасы эчендә ташуны тәэмин итә торган муниципальара әһәмиятле автомобиль юллары, тимер юл магистрале уза. Арча шәһәре күрсәтелгән магистраль транспорт коммуникацияләре кисешкән урыннарның үзәге булып тора.

АМР транспорт белән тәэмин ителешенең социаль индикаторы күрсәткече буенча транспорт челтәрләре уңайлыклары булган районнар төркеменә керә, анда әлеге күрсәткеч 1 сәгатьтән артмый.

АМРның табигый, социаль-икътисади, демографик шартларын үзара яраштыру АПК үсеше, сәнәгать һәм җитештерү-эшлекле функцияләр башкару өчен уңайлы.

### 4.2. Хезмәт базары

АМР Татарстан Республикасы муниципаль районнары арасында 2 балл белән бәяләнгән демографик йөкләнеш төркеменә керә (биш баллы шкала буенча уңай күрсәткеч 5 балл тәшкил итә, тискәре күрсәткеч- 1 балл).

2022 елда теркәлгән эшсезләр санының кимүе күзәтелә. Моннан тыш, эшсезләрнең 75% ын урта һәм югары һөнәри белемле АМР халкы тәшкил итә.

### 4.3. Инвестицион эшчәнлек

Төп капиталга инвестицияләр күләме (бюджет акчаларыннан тыш) соңгы 5 елда уңай динамикада саклана, һәм 2022 елның 6 аенда үсеш 2137 млн. сум тәшкил итте, бу өстенлекле АПК булган күп кенә районнардан шактый югары.

## 5. Социаль-икътисади үсешнең институциональ факторлары

АМР Стратегия -2030 да каралган икътисади зоналаштыру нигезендә Кама алды икътисади районына керә.

Стратегия - 2030 кысаларында Казан агломерациясенә керә торган Кама алды икътисади зонасының стратегик үсешенең өстенлекле юнәлеше - шәһәр һәм авыл җирлекләрен үстерү территорияләрен интеграцияләү.

Югарыда формалаштырылган максатларга һәм бурычларга ирешүдә кайбер проблемалар бар, аларның бер өлеше АМР стратегиясен гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган чорына система характерында. Әлеге проблемаларны хәл итү АМР дәрәҗәсендә идарәчел һәм хуҗалык карарларын кабул итү яссылыгында гына түгел, ә мондый карарларны республика һәм Россия Федерациясе дәрәҗәсендә кабул итү системасында.

АМР стратегиясен эшләүгә кадәр Кама алды икътисади зонасына керүче муниципаль районнар җитәкчеләре һәм белгечләре катнашында стратегик сессия уздыру эше барды. Ул АМР авыл җирлекләре башлыклары сораштырулары һәм институциональ матрица нигезенә яткан институциональ факторларны формалаштыру нәтиҗәләренә нигезләнеп төзелде.

6 нчы таблица. Институциональ матрица

| № | Институциональ факторлар | Эшчәнлек юнәлешләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Карар кабул итү дәрәҗәсе | АПК | Сәнәгать | Хезмәт күрсәтүләр өлкәсе | Кече һәм урта бизнес | Социаль өлкә | Торак-коммуналь хуҗалык | Төзелеш комплексы | Транспорт комплексы |
| 1 | **Икътисади бөтенлек** | җирле үзидарә органнары | | | | | | | | |
| 2 | **Инвестицион җәлеп итүчәнлек** | ҖҮО, ДХБО | | | | | | | | |
| 3 | **Эшлекле активлык** | җирле үзидарә органнары | | | | | | | | |
| 4 | **Шәһәрләшү (урбанизация)** | җирле үзидарә органнары | | | | | | | | |
| 5 | **Кеше капиталы һәм хезмәт базары** | җирле үзидарә органнары | | | | | | | | |
| 6 | **Дәүләт һәм муниципаль идарә** | ҖҮО, ДХБО | | | | | | | | |

6 нчы таблицадагы төсләрнең төрлелеге әлеге институциональ факторның, тулаем алганда, АМР социаль-икътисади үсеше һәм эшчәнлекнең аерым юнәлешләре өчен әһәмияте дәрәҗәсен характерлый.

Тәкъдим ителгән институциональ факторлар идарә карарларын кабул иткәндә, институциональ тозаклар барлыкка килүнең максималь куркыныч зоналарын идентификацияләү принцибы буенча сайлап алынды, алар, кагыйдә буларак, игътибар кимегәннән соң элекке халәтләренә кайталар, ә кайчак бу секторларда проблемаларны кискенләштерәләр. Өстәвенә һәр тозак мультипликацион характерга ия булырга һәм проблемалы секторларда яңа куркынычлар һәм янаулар барлыкка килүгә бәйле булырга мөмкин.

Моннан тыш, институциональ матрицада санап кителгән институциональ факторлар кысаларында карарлар формалаша торган идарә дәрәҗәсе билгеләнгән.

Түбәндә институциональ факторлар һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәр кысаларында проблемаларга кыскача характеристика китерелә.

Ачыкланган проблемаларны хәл итү буенча чаралар җыелмасы 13 нче таблицада китерелде.

Ачыкланган проблемаларның функциональ бәйлелеге 1 нче рәсемдә, АМР социаль-икътисади үсешенең төп проблемасында китерелде, анда республикада муниципаль һәм дәүләт идарәсенең җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавы билгеләнә.

Күренеп тора, чараларны гамәлгә ашыру шул исәптән финанс ресурсларын да таләп итәчәк. Аларның хисап күләме АМР Стратегиясендә китерелгән, әмма бюджет мөмкинлекләренә һәм башка инвестиция ресурсларына карап, шулай ук Стратегия - 2030 чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә карап, әлеге параметрлар АМР баланс комиссиясенә әлеге күләмнәрне нигезләгәннән һәм яклауны әзерләгәннән соң (бу хакта җентекләп «АМР Стратегиясен гамәлгә ашыру механизмы» исемле 7 бүлегендә бәян ителәчәк) билгеләнәчәк.

АМР Стратегиясе чаралары функциональ бәйлелектә тора. Бу бер чараны үтәмәү башка чараның срокларына яки эчтәлегенә яки аны чаралар исемлегеннән төшереп калдыруга, ә кайвакыт исемлеккә башка берничә чараны кертүгә дә йогынты ясарга мөмкин дигәнне аңлата. Бу бәйлелек 3 нче кушымтада китерелде.

## 5.1. Институциональ факторлар кысаларында проблемалар үзенчәлеге

### 5.1.1. Икътисади бөтенлек

АМРның икътисади бөтенлеге дигәндә АМРның керем потенциалы белән АМРга беркетелгән чыгым вәкаләтләре нисбәте дәрәҗәсе аңлашыла. Бу дәрәҗәне бәяләүнең төп индикаторы булып җирле бюджет кытлыгы тора.

АМР бюджеты бюджетара трансфертлардан файдаланып, чираттагы план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру процессында баланслана. Җирле бюджетта үзебезнең керемнәр өлеше 2021 елда 31% тәшкил итте.

Бюджет структурасы 7 нче таблицада күрсәтелде, 2021 елга бюджетның салым керемнәрендә төп өлешне 366 873 мең сум күләмендә НДФЛ (АМР территориясендә җыелган 81%) тәшкил итә.

Тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр һәм субвенцияләр күләме, шулай ук социаль өлкә оешмалары эшчәнлеген тәэмин итүгә, 1 075 853 мең сум тәшкил итә.

7 нче таблица. АМРның берләштерелгән бюджеты структурасы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 | 2018 | 2020 | 2021 | 2022 фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1. Җирле бюджет керемнәре** | мең сум | 1 038 564 | 1 310 455 | 1 420 328 | 1 601 794 | 1 673 963 |
| **1.1. Салым һәм салым булмаган керемнәр** | мең сум | 401 407 | 475 514 | 499 142 | 489 718 | 502 400 |
| **1.1.1. Салым керемнәре** | мең сум | 358 774 | 435 277 | 474 031 | 455 193 | 475 617 |
| физик затлар керемнәренә салым | мең сум | 270 466 | 335 712 | 363 591 | 366 873 | 386 246 |
| Җыелма керемгә салымнар: | мең сум | 26 049 | 30 628 | 30 931 | 43 274 | 38 324 |
| -патент рәвешендә алына торган салым | мең сум | 25 | 121 | 338 | 12 812 | 11 466 |
| - эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән керемгә бердәм салым | мең сум | 17 720 | 14 988 | 13 537 | 3 561 | 0 |
| - салым салуның гадиләштерелгән системасы | мең сум | 8 004 | 14 512 | 16 628 | 25 769 | 25 998 |
| - бердәм авыл хуҗалыгы салымы | мең сум | 300 | 1 007 | 428 | 1 132 | 860 |
| Физик затлар мөлкәтенә салым | мең сум | 8 367 | 9 168 | 11 964 | 11 727 | 13 514 |
| Җир салымы | мең сум | 25 280 | 27 564 | 32 572 | 29 326 | 32 923 |

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 | 2018 | 2020 | 2021 | 2022 фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт пошлинасы | мең сум | 5 067 | 3 486 | 4 204 | 3 294 | 4 204 |
| Нефть продуктларына акцизлар | мең сум | 23 556 | 28 153 | 30 388 | 36 224 | 40 500 |
| Башкалар | мең сум | -11 | 1 | 0 | 0 | 0 |
| **1.1.2. Салым булмаган керемнәр** | мең сум | 42 633 | 40 237 | 25 011 | 34 525 | 26 782 |
| дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | мең сум | 7 760 | 14 366 | 7 774 | 11 084 | 9 468 |
| матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | мең сум | 12 807 | 6 775 | 5 410 | 6 287 | 2 902 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | мең сум | 1 591 | 566 | 721 | 677 | 627 |
| штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | мең сум | 4 135 | 4 309 | 1 568 | 1060 | 500 |
| башка салым булмаган керемнәр | мең сум | 3 487 | 12 754 | 7 913 | 15 417 | 13 285 |
| **1.2. Башка дәрәҗәдәге бюджетлардан түләүсез керемнәр, шул** | мең сум | 641 807 | 835 545 | 937 668 | 1 075 853 | 1 131 064 |

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 | 2018 | 2020 | 2021 | 2022 фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **исәптән** | | | | | | |
| - дотацияләр | мең сум | 0 | 24 701 | 40 443 | 52 067 | 0 |
| - субвенцияләр | мең сум | 0 | 358 363 | 404 722 | 434 844 | 458 863 |
| - субсидияләр | мең сум | 0 | 390 926 | 387 696 | 417 078 | 558 479 |
| Татарстан Республикасының башка бюджетара трансфертлары | мең сум | 0 | 61 556 | 104 807 | 175 309 | 103 184 |
| кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | мең сум | 500 | 0 | 0 | 2 487 | 10 537 |
| узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кире кайтару | мең сум | -5 150 | -605 | - 16 482 | - 5 933 | 0 |
| **2. Җирле бюджет чыгымнары** | мең сум | 1 053 697 | 1 290 132 | 1 391 780 | 1 612 111 | 1 716 452 |
| гомумдәүләт мәсьәләләре | мең сум | 89 820 | 108 462 | 117 873 | 123 116 | 117 015 |
| милли оборона | мең сум | 2 179 | 2 197 | 2 580 | 2 499 | 2 588 |
| милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | мең сум | 989 | 2 769 | 3 421 | 3 122 | 3 873 |
| милли икътисад | мең сум | 24 067 | 112 013 | 95 230 | 119 310 | 127 280 |
| торак-коммуналь хуҗалык | мең сум | 131 420 | 73 258 | 96 973 | 95 338 | 84 057 |
| Әйләнә-тирә | мең сум | 1 449 | 308 | 966 | 1 405 | 1 239 |

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 | 2018 | 2020 | 2021 | 2022 фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|
| мохитне саклау | | | | | | |
| образование | мең сум | 688 497 | 825 385 | 832 622 | 994 169 | 1 088 783 |
| мәдәният, кинематография | мең сум | 81 804 | 124 597 | 132 863 | 171 986 | 170 692 |
| Сәламәтлек саклау | мең сум | 656 | 770 | 814 | 840 | 865 |
| социаль сәясәт | мең сум | 32 472 | 38 211 | 40 566 | 25 839 | 36 114 |
| физик культура һәм спорт | мең сум | 344 | 2 164 | 67 872 | 74 486 | 83 947 |
| массакүләм мәгълүмат чаралары | мең сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| муниципаль бурычны үтәү | мең сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| бюджетара трансфертлар | мең сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| **3. Профицит, кытлык (-)** | мең сум | -15 134 | 20 322 | 28 548 | - 10 317 | - 42 489 |

Социаль өлкә чыгымнарына килгәндә, аларның күләме республика дәрәҗәсендә билгеләнгән нормативлар нигезендә формалаштырыла. Әмма шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, хуҗалык субъектлары эшчәнлегеннән җирле бюджетка керемнәр арту, шулай ук бюджет оешмаларында бюджет акчаларын экономияләүдән елына җирле бюджетның гомуми күләме артмый, чөнки законнар нигезендә бу очракта бюджет трансфертлары күләме азрак була (чыгым вәкаләтләре үзгәрмәгән очракта).

Бюджет үсеше аз, шуңа күрә бу күләмнәр хисабына эре инвестицион проектларны гамәлгә ашыру мөмкин түгел. Моңа бәйле рәвештә, һичшиксез, бюджеттан тыш инвестицияләр җәлеп итүне, шулай ук АМРның республика һәм федераль проектларда катнашуын киңәйтү таләп ителә.

Шулай итеп, АМРның иң җитди проблемаларының берсе - бюджет кытлыгы һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне тиешле дәрәҗәдә хәл итү, шулай ук бюджет үсешен формалаштыру өчен өстәмә салым һәм салым булмаган керемнәр булмау.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: АМР территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кайбер предприятиеләр башка муниципаль берәмлекләрдә

теркәлгән, бу АМР бюджетын кермәгән салым керемнәренең бер өлеше турында сөйли.

АМР һәм аның составына керүче җирлекләр арасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштыру мәсьәләсен дә төгәлләштерү таләп ителә.

Түбәндә таблицада формалаштырылган проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән чаралар китерелә. Ләкин, шуны истә тотарга кирәк: AMR икътисади бөтенлегенең түбән дәрәҗәсен характерлаучы индикатор (институциональ фактор) башка институциональ факторлар кысаларында проблемаларны уңышлы чишү нәтиҗәсе. Бу бәйлелек түбәндәрәк күрсәтеләчәк.

8 нче таблица. Икътисади бөтенлек өлкәсендәге чаралар

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» илкүләм проекты кысаларында чараларны гамәлгә ашыру | 2019-2024 | АМР БК | | - |
| 2 | Арча муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүче субъектларны теркәүдә ярдәм | даими | АМР БК | | - |
| 3 | Арча муниципаль районы территориясенә инвесторларны җәлеп итү. | даими | АМР БК | | - |
| 4 | Бизнес-проектларны гамәлгә ашыру өчен буш җитештерү мәйданнарын сату | даими | АМР БК, җитештерү мәйданчыклары милекчеләре | | |
| 5 | Арча муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү. | даими | АМР БК | | - |
| 6 | Арча муниципаль районы территориясендә соры базар дәрәҗәсен киметү һәм хезмәткәрләргә хезмәт хакын арттыру | даими | АМР БК | | - |

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| | буенча эшләр алып бару. даими | | | | |
| 7 | Җитештерүчәнлекне арттыру максатында АМР хуҗалыклары һәм предприятиеләре производстволарын модернизацияләү | даими | Хуҗалык итүче субъектлар | | Үз һәм заем акчалары |

### 5.1.2 Инвестицион җәлеп итүчәнлек. Эшлекле активлык

Кагыйдә буларак, инвестицион җәлеп итүчәнлек дәрәҗәсе беренче нигезләмәнең ике факторына - инвестицион куркынычка һәм инвестицион потенциалга бәйле (кертемнәрдән табыш алу). Бу факторлар түбәндәге гамәлләрне кертергә мөмкин булган икенче нигезләмәгә бәйле:

-географик урнашу;

- ресурс-чимал;

- җитештерү (җитештерү булдыру һәм аның нәтиҗәләрен куллану өчен шартлар булу);

- кулланучылар (халыкның товарлар һәм хезмәтләр сатып алу сәләте характерлана);

- инфраструктура (мәгълүмат, транспорт, җитештерү инфраструктурасы, шулай ук инженерлык челтәрләренә тоташу мөмкинлеге);

- кирәкле сандагы һәм хезмәт ресурсларының сыйфаты буларак характерлана торган интеллектуаль.

АМРга килгәндә, аның географик урнашуы башка муниципаль районнарның күпчелегеннән республика башкаласы Казанга якын булуы белән аерылып тора. Шуның белән бергә, АМР административ үзәген Казан шәһәреннән (60 км ара) тоташтыручы юл нибары 12 метр киңлектә, (хәрәкәтнең ике полосасында), ягъни аның киңлеге транспорт-йөк ташуны үстерергә мөмкинлек бирми. Бүген Биектау районы чикләреннән алып Арча шәһәренә кадәрге участокта юлга йөкләнеш уртача нормада. Казан шәһәренә тоташа торган юл участогы дүрт тапкыр зуррак йөкләнешкә ия. Бу вәзгыять АМР Стратегиясе чараларын гамәлгә ашыруның беренче этабында (2021 елга кадәр) транспорт-йөк ташуны планлы арттыру өчен юлны реконструкцияләргә мөмкинлек бирми, моны АМР стратегиясен гамәлгә ашырганда күздә тотарга кирәк.

Яңа производстволар төзү яисә булганнарының куәтләрен үстерү кысаларында тулы инвентаризация булмаган буш яисә тулысынча файдаланылмаган җитештерү мәйданчыкларында инвестицион эшчәнлекне үстерү мөмкин.

АМРда халыкның уртача керемнәре республика дәрәҗәсеннән ике мәртәбә диярлек түбәнрәк. Кулланучылар ихтыяҗының этәргеч үсеше өчен керем югарырак булырга тиеш, шулай ук куллану тәкъдимнәре киңәйтелергә тиеш. Инде бүген үк район үзәгеннән ерак урнашкан авылларда аерым товарларга һәм хезмәтләргә бәяләрнең ваклап сатудагы кулланучылар товарлары бәясеннән 10-15 %ка югарырак булуы күренә. Өлешчә бу транспорт һәм башка операция чыгымнары нәтиҗәсе булып тора, ләкин, анализдан күренгәнчә, ваклап сату оешмалары монополиясе эшчәнлеге йогынтыны арттыра.

АМРда җирләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү, шулай ук АМР территориясендә эшчәнлек алып баручы кайбер оешмаларның салым исәбенә куелмавына бәйле рәвештә җирле бюджетка кемәгән керемнәре булу проблемалары бар. Кызганычка каршы, авыл җирлекләре территорияләренең актуаль генераль планнары, шулай ук җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру буенча республика программасы юк. Бу хәлләр АМР ның инвестицион җәлеп итүчәнлеген киметә, һәм АМР Стратегиясе билгеләгән чорга АМР ның ҖУО эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыруда киртәләр тудыра.

Шулай ук АМРда бизнес вәкилләре һәм халкының активлыгы җитәрлек дәрәҗәдә югары булмавын да билгеләп үтәргә кирәк. Бу әлеге субъектларның мәгълүматлылыгының түбән дәрәҗәдә булуы, финанс белеме югары булмавы һәм инвестицион проектлар буенча тәкъдимнәр булмау (муниципаль һәм дәүләт хакимияте органнары тарафыннан инициативалы һәм шулай ук) белән бәйле. АМРда товар җитештерүчеләренең, республиканың башка муниципаль берәмлекләренең һәм аннан читтә урнашкан регионнарның мөмкинлекләре һәм ихтыяҗлары (технологик чылбырлары) турында мәгълүмат эшлекле активлыкны арттыруга ярдәм итәр иде. Шулай ук, әгәр Татарстан товар җитештерүчеләре мондый мәгълүматны үзләре җитештерә торган продукция һәм номенклатураны киңәйтү буенча планнар нигезендә формалаштыра алса, Татарстан товар җитештерүчеләре турында мәгълүматны Кама алды икътисади зонасында төзелгән зональ маркетинг үзәге тарафыннан формалаштырылырга мөмкин булыр иде. Бу вәкаләтләрне товарлар һәм хезмәтләрне сатып алулар һәм сату турында мәгълүматның электрон базаларын администрацияләү буенча эре республика операторларының берсе, мәсәлән, Татарстан Республикасы дәүләт заказы агентлыгы башкара алыр иде.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү халыкның эшлекле активлыгын һәм мәшгульлеген арттыруның иң нәтиҗәле механизмнарыннан берсе булып тора. Әлеге механизм шулай ук авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең, авылда кече хуҗалыкларның һәм кулланучылар җәмгыятьләренең керемен арттырганда һәм аларны авыл җирендә тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе һәм азык-төлек базарларына кертүне тәэмин иткәндә, төп механизмнарның берсе булып тора. Әлеге механизмны куллану зарурлыгы Кама алды икътисади зонасына керүче муниципаль районнар җитәкчеләре һәм белгечләре катнашында узган стратегик сессия нәтиҗәләре белән расланды. Эшчәнлекнең әлеге юнәлеше АМР авыл җирлекләре башлыклары сораштырулары нәтиҗәләренә нигезләнеп билгеләнде һәм төзелде.

Әлеге юнәлешне үстерүнең алшартлары АМРның эчке потенциалы, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең АПК өлкәсендәге киң спектры, шулай ук күптән түгел генә расланган «2015 - 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасы белән бәйле (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2015 елның 21 октябрендәге 241\2 номерлы боерыгы).

Шул рәвешле, әлеге институциональ фактор кысаларында, түбәндәге проблемалар исемлеген формалаштырырга мөмкин:

- киләсе өч елда магистральләрнең үткәрү сәләтен арттыру максатында Арча һәм Казан шәһәрләре арасында юлның аерым участокларын киңәйтү перспективасы булмау;
- АМР торак пунктлары арасында каты өслекле юллар булмау;
- инвестиция тәкъдимнәрен булдыру өчен мәгълүмати технологияләрнең кулланылмавы һәм инвесторлар өчен башка файдалы мәгълүмат технологияләренең кулланылмавы;
- җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге булмау;
- технологик чылбырлар турында АМР эчендә дә, аның территориясеннән читтә дә мәгълүмат булмау;
- авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан төзелгән АМР эшчәнлегенең төп юнәлешләре: авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча кооперациянең көчле системасы булмау;
- авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең гамәлдәге һәм төзелә торган җитештерү куәтләрен булдыру һәм модернизацияләү өчен шартлар булмау;
- җирлекләрнең генераль планнары булмау.

9 нчы таблицада санап үтелгән проблемаларны хәл итү өчен чаралар исемлеге китерелде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 6 нчы таблицада китерелгән чаралар шулай ук әлеге проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

9 нчы таблица. Инвестицион җәлеп итүчәнлек һәм эшлекле активлык һәм эшлекле активлык өлкәсендәге гамәлләр

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Районда булган ресурсларны исәпкә алып, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең перспектив юнәлешләре турында потенциаль инвесторлар өчен мәгълүмат әзерләү һәм бирү | даими | АМР БК | | |

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | АМРда электрон сәүдә үсеше өчен уңай шартлар тудыру | даими | АМР БК | | |
| 3 | АМРда икътисад тармаклары өчен уңайлы шартлар тудыру | | | | |
| 4 | Файдаланылмый торган җитештерү мәйданнары, шул исәптән, җитештерү һәм инфраструктура объектларын урнаштыру өчен яраклы җир кишәрлекләре реестрын инвентаризацияләү һәм формалаштыру | даими | АМР БК | | |
| 5 | Кулланылмый торган яки нәтиҗәле кулланылмаган милекне һәм шәхси милектә булган җирләрне бизнес әйләнешенә җәлеп итү | даими | АМР БК | | |
| 6 | АМР, күрше муниципаль берәмлекләр һәм АМР белән уртак чиге булган регионнар буенча төп кулланучылар товарлары һәм хезмәт күрсәтүләр буенча базар сыйдырышлылыгына анализ ясау | даими | АМР БК | | |
| 7 | Инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итә торган потенциаль инвесторлар өчен презентация очрашулары оештыру һәм уздыру | даими | АМР БК | | |

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Эшкуарлар һәм икътисади актив булмаган халык белән стратегик сессия үткәрү | квартал саен | АМР БК , эшкуарларны чакырып | | |
| 9 | Яңа Кенәр авылында муниципаль сәнәгать паркын төзү | 2022-2023 ел | АМР БК | | |
| | ***Инвестицион проектларны гамәлгә ашыру, шул исәптән:*** | | | | |
| 1 | «Арча» ҖЧҖ ярымкаты сыр җитештерү өчен яңа автоматик линия төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, "Арча" ҖЧҖ | 570 000 | Бюджеттан тыш |
| 2 | «Системалы йорт» ҖЧҖ автомобиль сәнәгате өчен нефть химиясе компонентлары җитештерү заводы | 2020-2022 ел | ИК АМР, «Системалы йорт» ҖЧҖ | 120 000 | Бюджеттан тыш |
| 3 | «ТехноАрск» ҖЧҖ металл конструкцияләр җитештерү, терлекчелек комплекслары өчен абзар җиһазлары һәм башка металл эшләнмәләр заводын төзү | 2020-2023 ел | АМР БК, "Техноарск" ҖЧҖ | 260 000 | Бюджеттан тыш |
| 4 | «Кырлай» АФ» ҖЧҖ 1800 башка исәпләнгән сөтчелек комплексы төзелеше | 2021-2024 ел | АМР БК, «Кырлай» АФ» ҖЧҖ | 240 000 | Бюджеттан тыш |
| 5 | "Тайд-Фойл" ҖЧҖ фирмасы эретелгән төенле цементны бушату һәм тутыру үзәген төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, «Тайд-Фоил» ҖЧҖ фирмасы | 90 000 | Бюджеттан тыш |
| 6 | Авыл хуҗалыгын эшкәртү проектын гамәлгә ашыру: сөтне пакетларга тутыру, катнаш азык җитештерү, «Куе сөт алмаштыргычлар | 2019-2022еллар | АМР БК хосусый инвесторлар | 160 000 | Бюджеттан тыш |

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| | катнаш азык җитештерү, «Куе сөт алмаштыргычлар, премикслар һәм катнаш азык җитештерү буенча Идел буе заводы» | | | | |
| 7 | «Возрождение» АФ» ҖЧҖ 1200 башка исәпләнгән сөт комплексы төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, «Возрождение» АФ» ҖЧҖ | 360 000 | Бюджеттан тыш |
| 8 | «Северный» АХП» ҖЧҖ 6000 башка исәпләнгән мегакомплекс төзү | 2022-2026 ел | АМР БК, «Северный» АХП» ҖЧҖ | 3 800 000 | Бюджеттан тыш |

### 5.1.3 Кеше капиталы һәм хезмәт базары. Шәһәрләшү (урбанизация)

Урбанизациянең җитди проблемаларының берсе аның стихияле характерда булуы, бу торак урыны һәм эш урыны булмаган авыл халкының шәһәргә китү проблемасының кискенләшүенә китерә. Бу процесста авыл территорияләрендә яшәүчеләрнең урта һәм югары уку йортларында укуы төп фактор булып тора, һәм, кагыйдә буларак, төп тарту үзәге булып Казан шәһәре тора. Бу проблема мультиплиция характерында, чөнки башкаланың хезмәт базарына һәм аның инфраструктурасына йөкләнеш арта, шулай ук АМР ның хезмәткә сәләтле халкы өлеше сизелерлек кими.

Шуны билгеләп үтү мөһим: урбанизация шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы җитештерүе кимүгә китерә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бигрәк тә Арча шәһәре яшьләрне җәлеп итү үзәге булып тора, чөнки Арча шәһәрендә тормыш сыйфаты, хезмәт хакы дәрәҗәсе, ял итү урыннары күләме яшьләрнең авыллардан күчеп китү факторлары булып тора. Тулаем алганда, АМР хезмәт базары икътисади мөнәсәбәтләрнең катлаулы системасын тәшкил итә. Хезмәт базарының төп элементлары - чынлыкта эшләүчеләр, эшсезләр, "соры" хезмәт базарында, шулай ук ҖҮОда эшләүчеләр. 2022 елның 1 октябренә хезмәт базарының торышы 10 нчы таблицада күрсәтелде.

10 нчы таблица. 2022 елның 1 октябренә АМРда хезмәт базарының торышы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 1 окт. 2022 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе | % | 0,47 | 0,50 | 1,16 | 0,44 | 0,35 |
| ТР буенча теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе | % | 0,50 | 0,54 | 1,90 | 0,56 | 0,49 |
| Эшсез статусына ия гражданнар саны (мәшгульлек хезмәтендә исәптә торучы эшсез гражданнар арасыннан) | кеше | 120 | 128 | 295 | 112 | 88 |
| МОТ методологиясе буенча эшсезлек дәрәҗәсе | % | 2,7 | 2,7 | 3,1 | ... | ... |

Мәшгульлек хезмәтенә мөрәҗәгать иткән АМР кешесенең типик портреты - элек үз теләге белән эштән киткән хезмәткәр. Эшсезләрнең югары һәм урта һөнәри белемле булуы мөһим параметр булып тора (75%), бу профессиональ кадрлар кытлыгы булганда өстәмә анализ таләп итә. Бәлки, эшсезлек буенча пособие күләме шактый югары булган (уртача республика дәрәҗәсендә диярлек) соры хезмәт базарының үсеше дә бардыр. Ә һөнәри кадрларга кытлык һәм стратегик сессияләрдә барлык төркемнәр тарафыннан формалаштырылган һөнәри белем алу мөмкинлеге булмау проблемасын исәпкә алып, бу хәл тагын да мөһимрәк була бара.

АМРда хезмәт хакы республика буенча уртача һәм аннан да югарырак булган эш урыннары саны 44 % тәшкил итә. АМР буенча уртача хезмәт хакы республикадагы уртача хезмәт хакыннан 30 %ка диярлек түбәнрәк. Авыл халкының пенсиясе уртача республика күләменнән шактый түбән булуын исәпкә алып, АМР халкының көндәлек кирәк-ярак товарларга, шулай ук озак куллану товарларына ихтыяҗын канәгатьләндерү буенча җитди проблема килеп туа. Пенсияләр күләме төбәк дәрәҗәсендә үзгәртелә алмый, чөнки бу федераль ДХБО вәкаләтләренә карый, әмма пенсия яшендәге гражданнарның керемнәрен күтәрү аларны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү юлы белән генә мөмкин, бу өлкәдә башка төбәкләрнең иң яхшы тәҗрибәләре дә раслана.

Арча шәһәре һәм Казан шәһәрен тоташтыручы транспорт коммуникацияләрен реконструкцияләү мәсьәләләрен хәл иткәндә яшәү һәм эшкә урнашу өчен яшьләрнең Казан шәһәренә китүе дә артырга мөмкин.

Әгәр бу процессларның көчәюен булдырмау буенча алдан ук кисәтү чаралары күрсәк, хезмәт ресурсларының читкә китүен туктатырга һәм хәтта хезмәт ресурсларын башка территорияләрдән җәлеп итәргә мөмкин.

Шулай итеп, кеше капиталын үстерү һәм хезмәт базары балансы өлкәсендәге проблемалар сыйфатында түбәндәгеләрне формалаштырырга мөмкин:

- урта һәм югары һөнәри белеме булган хезмәткә сәләтле яшьтәге кешеләр арасында эшсезлекнең югары дәрәҗәсе;

- АМР да уртача хезмәт хакыннан югарырак булган эш урыннары булмау;

- түбән хезмәт хакы;

- түбән пенсия.

11 нче таблицада формалаштырылган проблемаларны хәл итү өчен чаралар исемлеге китерелде.

11 нче таблица. Кеше капиталы, хезмәт базары һәм урбанизация өлкәсендәге гамәлләр

| *№* | *Чара* | *Башкару сроклары* | *Җаваплы башкаручы* | *Финанслау күләме, мең сум.* | *Чыгана клар* |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Вакансияләр һәм эшкә өйрәтү урыннары ярминкәләрен үткәрү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |
| 2 | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша булган буш эш урыннары турында халыкка һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |
| 3 | Фаразлы бәяләүне исәпкә алып, хезмәт базарының «тар урыннар»ына анализ ясау | 2023 ел | АМР БК | | |
| 4 | Районда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда, шул исәптән мәктәптә дә, яшьләрнең иртә һөнри практика системасын булдыру<br>-яшьләрнең, укучыларның теләкләрен исәпкә алып; | 2023-2025 еллар | АМР БК | | |

| № | *Чара* | *Башкару сроклары* | *Җаваплы башкаручы* | *Финанслау күләме, мең сум.* | *Чыганаклар* |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру. | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |
| 6 | Районның сәнәгать һәм аграр секторы оешмаларының һәм Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары укучыларын җыю һәм Арча муниципаль районының профильле оешмалары өчен максатчан әзерлек буенча көчләрен берләштерү; | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |
| 7 | Арча муниципаль районында башлангыч һөнәри юнәлеш системасын кертү | 2020-2023 еллар | АМР БК | | |
| 9 | Эшсез гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләре үткәрүне оештыру | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |
| 10 | Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык итү, эшкуарлык эшчәнлеген теркәгәндә аларга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру, фараз буенча, хезмәткә сәләтле халык санын, АМР халкының гомуми санын һәм эшлекле активлыкны арттыруга китерергә мөмкин.

### 5.1.4. Дәүләт һәм муниципаль идарә

Авыл җирлекләре җитәкчеләре һәм бизнес вәкилләре белән үткәрелгән стратегик сессия нәтиҗәләре буенча «дәүләт һәм муниципаль идарә» институциональ факторының төп роле белән бәйле АМР социаль-икътисади үсеше проблемасы ачыкланды һәм дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәле системасы буларак формалаштырылды.

Билгеле булганча, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәсе (корпоратив хәл ителешләр кебек үк) булып идарәче карарлар тора. Әлеге карарлар норматив хокукый актлар һәм карарларның башка формалары рәвешендә рәсмиләштерелә һәм дәүләт һәм муниципаль идарәнең гомуми системасына интеграцияләнергә тиеш. Татарстан Республикасында мондый система сыйфатында икътисад белән индикатив идарә итү системасы сайланды. Аның кысаларында инде 15 ел дәвамында һәр ДБХО өчен чираттагы һәм алдагы ике елга идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе формалаша. Бу чор бюджет планлаштыру чоры белән билгеләнә.

ҖҮО өчен ел саен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары тарафыннан килешүләр төзелә һәм имзалана, аларда аерым дәүләт вәкаләтләре кысаларында ҖҮО эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре чагыла, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Шәһәр округлары һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Указы белән билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон ДХБО һәм ҖҮО хезмәттәшлеге системасын катлауландырды. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең, еш кына объектив зарурлык булса да, ҖҮОна күрсәтмә бирергә хакы юк.

Әлеге баскычлар арасындагы конструктив сөйләшүне җайга салу максатында, республикада Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелде, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләрен мөһим проблемалар буенча бәхәсле мәйданчыкка даими рәвештә җыю гамәлгә ашырыла. Видеоконференция режимында уздырыла торган киңәшмәләрне нәтиҗәле инструмент дип санарга мөмкин. Алар оператив мәгълүмат алырга һәм кичектергесез карарларны килештерергә мөмкинлек бирә.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән социаль-икътисади үсешнең үз стратегияләрен эшләү буенча ҖҮО вәкаләтләре билгеләнде. Әмма, күрәсең, стратегиялнең һәм программалаштыруның билгеләнгән технологияләре өчен әлеге эшләрне республика дәрәҗәсендә шундый ук процесслар белән синхронлаштыру регламентлары кирәк. Мәсәлән, авыл җирлекләренең генераль планнары булмау, территориаль планлаштыруның актуаль схемалары, җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программалары булмау, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру буенча канәгатьләнерлек бәяләр булмау, программалар һәм проектлар белән идарә итүнең бердәм үзәге булмау шартларында фаразлауны, планлаштыруны, мониторингны, контрольне һәм җайга салуны үз эченә алган муниципаль идарәнең нәтиҗәле

системасын төзү мөмкин түгел диярлек. Нәкъ менә шуңа күрә барлык муниципаль программалар да диярлек "ритуаль" программалар характерында (алар регламент буенча булырга тиеш), аларга белгечләр үзләренең агымдагы эшчәнлегендә сирәк мөрәҗәгать итә. Бер генә дәүләт программасы да тулы күләмдә гамәлгә ашырылмаган (мәсәлән, АМР Стратегиясен эшләгәндә 2011-2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү программасы үтәлешенә анализ ясалды (алга таба - 2011-2015 ПСЭР), ул күрсәткәнчә, АМР Стратегиясе тәкъдим иткән чараларның төп өлеше 2011-2015 ПСЭРда планлаштырылган булган, ләкин алар үтәлмәгән).

Вәзгыять «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 15 мартындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы кабул ителгәннән соң тагын да катлауланды, ул дәүләт һәм муниципаль идарә системаларының мөһим элементы буларак агломерация һәм зональ идарәне билгеләде. Шул ук вакытта бүгенге көнгә ҖҮО һәм ДХБО, бизнес һәм җәмәгатьчелек вәкилләре, шулай ук бүген мондый хезмәттәшлек кысаларында төзелгән институтларның үзара хезмәттәшлеге регламентларын билгели торган норматив хокукый актлар юк. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2011-2015 елгы ПСЭРны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре һәм әлеге идарә карарлары формалаштырылырга тиеш иде.

Бер генә муниципаль район да, бигрәк тә җирлек тә автоном рәвештә үсә алмаганга күрә, муниципальара коммуникацияләр һәм муниципальара проектлар һәм программалар эшләү һәм кабул итү технологиясе дә юк.

Шуның белән бергә, АМРда икътисад һәм идарә итү карарлары хакимиятнең югары баскычында кирәкле мәсьәләләрне хәл итүнең вакытына һәм тулылыгына бәйле булуын исәпкә алып, бу хәл АМР стратегиясендә компенсаторлы һәм, мөгаен, һәрвакытта да мөмкин кадәр нәтиҗәле карарлар куллануга китерә, шуңа күрә аларның карарларын лоббилаштыру агломерация идарәсенең (икътисади зона) иҗтимагый советларын булдыру коралы аша гамәлгә ашырылачак, аның җитәкчеләре республика дәрәҗәсендә төп үсеш институтларына керә (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвестицион Совет, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисади Совет).

Шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү системасы да артык формаль. Бер программа кысаларында төрле һөнәри мәнфәгатьләре һәм белгечлекләре булган зур төркемнәр формалаштыру планлаштырылган белем бирү программаларыннан кирәкле нәтиҗә алырга мөмкинлек бирми.

ҖҮОда соңгы берничә елда берничә тапкыр персонал саны кыскарды, бу муниципаль берәмлекләрне төрле оештыру-хокукый юнәлештә оештырды, алар шулай ук бюджет чаралары хисабына тотыла һәм ҖҮО функцияләрен башкара.

Республика ДХБО тарафыннан соратып алынган мәгълүмат күләме даими рәвештә арта. Беренчел бәяләүләр буенча, ҖҮО белгечләре эш вакытының кимендә 50% ында хисаплылык әзерләү белән мәшгуль.

Гомумән алганда, бу өлкәдә түбәндәге проблемаларны формалаштырырга мөмкин (аларны санаганда, алдагы бүлекләрдә аларны санау факты исәпкә алынды):

- агломерация үсеше турында норматив хокукый актлар булмау;

- муниципальара проектларны һәм программаларны килештерү механизмы булмау;

- проектлар һәм программаларны эшләүне һәм мониторинглауны, шулай ук ресурсларны бер программадан икенчесенә күчерү буенча тәкъдимнәр әзерләүне координацияләү өчен җаваплы бердәм республика органы булмау;

- ҖҮОның типик структурасы булмау;

- ДХБО соратып ала торган хисап мәгълүматының күләме арту;

- ҖҮО хезмәткәрләренә аларның эш нәтиҗәләре буенча түләмәү.

Алдагы бүлекләрдә өстәмә тасвирланган әлеге проблемаларны хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.

12 нче таблица. Дәүләт һәм муниципаль идарә өлкәсендәге чаралар

| *№* | *Чара* | *Башкару сроклары* | *Җаваплы башкаручы* | *Финанслау күләме, мең сум.* | *Чыганаклар* |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Оператив социаль-икътисади планнар төзү һәм аларның үтәлешенә агымдагы контроль | квартал саен | АМР БК | | |
| 2 | АМР территориясендә планнарны һәм программаларны гамәлгә ашыруга гомуми җитәкчелек | даими | АМР БК | | |
| 3 | АМР яшәешен тәэмин итү буенча эшчәнлекне координацияләү һәм аның нәтиҗәлелеген тикшереп тору | даими | АМР БК | | |
| 4 | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру | даими | АМР БК | | |

Алдагы бүлекләрдә санап үтелгән чараларның җыелма таблицасы 13 нче таблицада китерелде.

13 нче таблица. Институциональ факторлар буенча чаралар җыелмасы

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» илкүләм проекты кысаларында чараларны гамәлгә ашыру | 2019-2024 | АМР БК | | - |
| 2 | АМРда электрон сәүдә үсеше өчен уңай шартлар тудыру | даими | АМР БК | | |
| 3 | АМРда икътисад тармаклары өчен уңайлы шартлар тудыру | даими | АМР БК | | |
| 4 | Арча муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүче субъектларны теркәүдә ярдәм | даими | АМР БК | | - |
| 5 | Арча муниципаль районы территориясенә инвесторларны җәлеп итү | даими | АМР БК | | - |
| 6 | Бизнес-проектларны гамәлгә ашыру өчен буш җитештерү мәйданнарын сату | даими | АМР БК, җитештерү мәйданчыклары милекчеләре | | |
| 7 | Арча муниципаль районы | даими | АМР БК | | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү | | | | |
| 8 | Арча муниципаль районы территориясендә соры базар дәрәҗәсен киметү һәм хезмәткәрләргә хезмәт хакын арттыру буенча эшләр алып бару | даими | АМР БК | | - |
| 9 | Җитештерүчәнлекне арттыру максатында АМР хуҗалыклары һәм предприятиеләре производстволарын модернизацияләү | даими | Хуҗалык итүче субъектлар | | Үз һәм заем акчалары |
| 10 | Районда булган ресурсларны исәпкә алып, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең перспектив юнәлешләре турында потенциаль инвесторлар өчен мәгълүмат әзерләү һәм бирү | даими | АМР БК | | |
| 11 | Файдаланылмый торган җитештерү мәйданнары, шул исәптән, җитештерү һәм инфраструктура объектларын урнаштыру өчен яраклы җир кишәрлекләре реестрын инвентаризацияләү һәм формалаштыру | даими | АМР БК | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Кулланылмый торган яки нәтиҗәле кулланылмаган милекне һәм шәхси милектә булган җирләрне бизнес әйләнешенә җәлеп итү | даими | АМР БК | - | - |
| 13 | АМР, күрше муниципаль берәмлекләр һәм АМР белән уртак чиге булган регионнар буенча төп кулланучылар товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре буенча базар сыйдырышлылыгына анализ ясау | даими | АМР БК | | |
| 14 | Инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итә торган потенциаль инвесторлар өчен презентация очрашулары оештыру һәм уздыру | даими | АМР БК | | |
| 15 | Эшкуарлар һәм икътисади актив булмаган халык белән стратегик сессия үткәрү | квартал саен | АМР БК , эшкуарларны чакырып | | |
| 16 | Яңа Кенәр авылында муниципаль сәнәгать паркын төзү | 2022-2023 ел | АМР БК | | |
| | ***Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, шул исәптән:*** | | | | |
| 1 | «Арча» ҖЧҖ ярымкаты сыр җитештерү өчен яңа автоматик линия төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, "Арча" ҖЧҖ | 570 000 | Бюджеттан тыш |
| 2 | «Системалы йорт» ҖЧҖ автомобиль сәнәгате өчен нефть химиясе компонентлары | 2020-2022 ел | ИК АМР, «Системалы йорт» ҖЧҖ | 120 000 | Бюджеттан тыш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җитештерү заводы | | | | |
| 3 | «ТехноАрск» ҖЧҖ металл конструкцияләр, терлекчелек комплекслары өчен абзар җиһазлары һәм башка металл эшләнмәләр җитештерү заводы төзү | 2020-2023 ел | АМР БК, "Техноарск" ҖЧҖ | 260 000 | Бюджеттан тыш |
| 4 | «Кырлай» АФ» ҖЧҖ 1800 башка исәпләнгән сөтчелек комплексы төзү | 2021-2024 ел | АМР БК, «Кырлай» АФ» ҖЧҖ | 240 000 | Бюджеттан тыш |
| 5 | "Тайд-Фойл" ҖЧҖ фирмасы эретелгән төенле цементны бушату һәм тутыру үзәген төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, «Тайд-Фоил» ҖЧҖ фирмасы | 90 000 | Бюджеттан тыш |
| 6 | Авыл хуҗалыгын эшкәртү проектын гамәлгә ашыру: сөтне пакетларга тутыру, катнаш азык җитештерү, «Куе сөт алмаштыргычлар, премикслар һәм катнаш азык җитештерү буенча Идел буе заводы» | 2019-2022еллар | АМР БК хосусый инвесторлар | 160 000 | Бюджеттан тыш |
| 7 | «Возрождение» АФ» ҖЧҖ 1200 башка исәпләнгән сөт комплексы төзү | 2020-2022 ел | АМР БК, «Возрождение» АФ» ҖЧҖ | 360 000 | Бюджеттан тыш |
| 8 | «Северный» АХП» ҖЧҖ 6000 башка исәпләнгән мегакомплекс төзү | 2022-2026 ел | АМР БК, «Северный» АХП» ҖЧҖ | 3 800 000 | Бюджеттан тыш |
| **№** | **Чара** | **Башкару сроклары** | **Җаваплы башкаручы** | **Финанслау күләме, мең сум** | **Чыганаклар** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Вакансияләр һәм эшкә өйрәтү урыннары ярминкәләрен үткәрү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |
| 18 | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша булган буш эш урыннары турында халыкка һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |
| 19 | Фаразлы бәяләүне исәпкә алып, хезмәт базарының «тар урыннар»ына анализ ясау | 2023 ел | АМР БК | | |
| 20 | Районда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда, шул исәптән мәктәптә дә, яшьләрнең иртә һөнәри практика системасын булдыру<br>-яшьләрнең, укучы балаларның теләген исәпкә алып; | 2023-2025 еллар | АМР БК | | |
| 21 | Эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |
| 22 | Районның сәнәгать һәм аграр секторы оешмаларының һәм Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары укучылар җыю һәм Арча муниципаль районының профильле оешмалары өчен максатчан әзерлек буенча көчләрен берләштерү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 23 | Арча муниципаль районында башлангыч һөнәри юнәлеш системасын кертү | 2020-2023 еллар | АМР БК | | |
| 24 | Эшсез гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләре үткәрүне оештыру | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |
| 25 | Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык итү, эшкуарлык эшчәнлеген теркәгәндә аларга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтү | 2020-2023 еллар | АМР БК, Арча шәһәре халыкны эш белән җәэмин итү үзәге ДКУ | Агымдагы финанслау | |
| 26 | Оператив социаль-икътисади планнар төзү һәм аларның үтәлешенә агымдагы контроль | квартал саен | АМР БК | | |
| 27 | АМР территориясендә планнарны һәм программаларны гамәлгә ашыруга гомуми җитәкчелек | даими | АМР БК | | |
| 28 | АМР яшәешен тәэмин итү буенча эшчәнлекне координацияләү һәм аның нәтиҗәлелеген тикшереп тору | даими | АМР БК | | |
| 29 | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру | даими | АМР БК | | |

Программаны гамәлгә ашыруда мөһим әһәмияткә ия булган институциональ матрицаның төп блогына кермәгән яшәеш иминлеге юнәлешендә өстәмә чаралар (Татарстан Республикасы Экология министрлыгы һәм Татарстан Республикасы

буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының искәрмәләре һәм тәкъдимнәре нигезендә кертелде) (12 таблица).

14 нче таблица

| № | Чара | Башкару сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләмнәре (мең сумнарда) | Чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Экологик куркыныч производстволарны, корылмаларны инвентарьләштерү һәм калдыкларны күмү | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 2 | Рөхсәтсез чүплекләрне мониторинглау һәм бетерү | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 3 | Экологик куркыныч объектларның кадастрларын төзү һәм алып бару | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 4 | Ел саен «Агач утырту көне» үткәрү | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 5 | ТБО эшкәртү өлкәсендә инвестиция проект булдыру һәм гамәлгә ашыру | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 6 | АМР гидротехник корылмаларын ремонтлау | 2019-2030 еллар | АМР БК | Финанслаганда | ТР |
| 7 | Казансу елгасы үзәнен үзгәртү чаралары | 2019-2030 еллар | АМР БК | Финанслаганда | ТР |
| 8 | Район юл челтәренең техник торышын һәм аннан файдалануны комплексны тикшерү үткәрү | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 9 | Светофор объектларын урнаштыру һәм хәрәкәтне чикләү буенча башка чаралар | 2019-2030 еллар | АМР БК | | |
| 10 | Районның торак | 2019- | АМР БК | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | пунктларына керү юлларын төзү һәм ремонтлау | 2030 еллар | | | |

Программаны гамәлгә ашыруда мөһим әһәмияткә ия булган институциональ матрицаның төп блогына кермәгән сәламәтлек саклау юнәлешендәге өстәмә чаралар (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдиме нигезендә кертелде (13 нче таблица)

Төп максат: сәламәтлек саклау һәм гомерне озайту. Хәзерге демографик шартларда сәламәтлек мәсьәләсен иң актуаль дип санарга мөмкин.

**Бурычлар:**

- халыкка сыйфатлы һәм арзанлы медицина ярдәме күрсәтү;
- медицина хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларны актив җәлеп итеп, профилактика кластерын алга таба үстерү;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча коммуникация компаниясе үткәрү;
- халыкка беренчел медицина-санитария ярдәмен камилләштерү;
- «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклау» Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын камилләштерү һәм алга таба үстерү;
- дәвалауның югары технологияле ысулларын алга таба үстерү, халыкка, шул исәптән авыл халкына, җиткерүне тәэмин итү;
- тармакның кадрлар потенциалын үстерү;

15 нче таблица. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге чаралар

| | **Чара** | **Башкару сроклары** | **Җаваплы башкаручы** | **Финанслау күләме, (мең сумнарда)** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Халыкның актив тормыш озынлыгын түбәндәгеләр исәбенә арттыру:<br>- сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру һәм авыруларны профилактикалау; миокард инфаркты һәм инсульт белән авыручыларны киметү.<br>-авыруның I - II стадиясендә яман шеш белән авыручыларны ачыклауны арттыру;<br>-туберкулезы башлангыч стадиядә ачыкланган авырулар | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өлешен арттыру;<br>-эчкечелек, наркоманлык белән авыручылар санын киметү | | | |
| 2. | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша, профилактик акцияләр һәм үнкөнлекләр кысаларында йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру системасын үстерү, шул исәптән балаларда.<br>Тәмәке, хәмер, наркотик чаралар һәм психоактив матдәләр куллануны киметүне дә кертеп, бәйлелек үсешен профилактикалау, шул исәптән балаларда | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 3 | Түбәндәгеләрне оештыру һәм уздыру:<br>- өлкән яшьтәге халыкның билгеле бер төркемен диспансерлаштыру;<br>-ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, шул исәптән опекага (попечительлеккә) алынган, тәрбиягә яки патронат гаиләгә алынган балаларны диспансерлаштыру;<br><br>- балигъ булмаганнарга профилактик медицина күзәтүе үткәрү. | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 4 | Арча районы халкына беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтә торган сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту: | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | ТР бюджеты |
| | -яңа модульле ФАПлар төзүне дәвам итү;<br>-район үзәк хастаханәсенең, авыл сәламәтлек саклау учреждениеләренең гамәлдәге биналарын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау, шул исәптән | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | ТР бюджеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | ФАПларны авыл мәктәпләре биналарына, төзелеп килүче күп функцияле үзәкләргә күчерү. | | | |
| | Арча районы халкының югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә ихтыяҗын тәэмин итү, әлеге категориядәге затларны квоталар нигезендә Федераль һәм Республика дәвалау учреждениеләренә җибәрү | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| | Бала үсешендә бозылулар пренаталь (бала тудырганга кадәр) диагностикалауны оештыру һәм уздыру | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| | Сәламәтлек саклауда менеджменты сыйфатының заманча принципларын кертү | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 5.1 | Медицина кадрларының квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерлек | 2019-2030 | "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ, КГМА | |
| 5.2 | Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре бирү программасы кысаларында ("Земский врач") белгечләрне җәлеп итү эшен башкару | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 5.3 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табиб-белгечләргә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 елның 25 февралендәге 120 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү программасы кысаларында белгечләрне җәлеп итү эшен башкару | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 5.4 | Муниципаль берәмлекләр өчен табибларны адреслы әзерләүнең социаль программасын гамәлгә ашыру (табиб кадрларына | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ихтыяҗ булган муниципаль берәмлектә укыту бәясенең 50 процентын муниципаль берәмлек бюджетыннан һәм 50 процентын укучы үзе түләү шарты белән) | | | |
| 6. | Аерым категориядәге гражданнарның дару препаратларына һәм медицина кирәк-яракларына ихтыяҗын тәэмин итү. Дарулар белән тәэмин итү системасын камилләштерү, шул исәптән амбулатор шартларда | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |
| 7. | Сәламәтлек саклау тармагын мәгълүматлаштыру | 2019-2030 | «Арча РҮХ» ДАССУ | |

Чараларны гамәлгә ашырудан түбәндәгеләр көтелә:

- сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру һәм авыруларны профилактикалау исәбенә халыкның актив гомер озынлыгын арттыру;

-йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан авыручылар һәм үлүчеләр санын киметү;

-авыруның I -II стадиясендә яман шеш авыруы белән авыручыларны ачыклауны арттыру, бер ел эчендә үлү һәм авыру көчәюләрне киметү.

Институциональ матрицаны анализлау нигезендә һәм институциональ факторларның АМРда тәкъдим ителгән эшчәнлекнең тиешле юнәлешләренә йогынтысы кысаларында алдагы бүлекләрдә АМРның социаль-икътисади үсешенә комачаулый торган санап үтелгән проблемалар формалаштырылды. 1 нче рәсемдә ачыкланган төп проблемалар һәм аларның функциональ сәбәп-тикшерү бәйләнешләре күрсәтелде.

1 нче рәсем. Функциональ сәбәп-тикшерү бәйләнешләре




## 6. АМР Стратегиясен гамәлгә ашыру сроклары

Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсеше стратегиясе 15 елга (2016 - 2030 еллар) билгеләнде һәм дүрт этапны (өч өчьеллык һәм бер алтыеллык) күздә тота. Шул ук вакытта, кирәк булганда, өч елга бер тапкыр төзәтмә кертеләчәк, ә алты елга бер тапкыр Стратегия яңартылачак.

Гамәлгә ашыру этаплары социаль-икътисади үсеш шартлары, факторлары, куркынычлары һәм районның икътисади сәясәте өстенлекләре буенча аерылалар.

Беренче этап (2016 - 2018 еллар) икътисадның нәтиҗәлелеген һәм аның белән идарә итүне арттыру, кеше капиталының сыйфатын үстерү һәм конкурентлык сәләтен җитди үстерү максатында район икътисады ия булган конкурентлык өстенлекләрен гамәлгә ашыруга һәм киңәйтүгә нигезләнә. Әлеге этапта, төп икътисади юнәлешләрне үстерү программасын булдырып, дәүләт программалары системасын төзергә, өстенлекле үсеш проектлары җыелмасын эшләргә кирәк булачак.

Стратегиянең беренче этабы дәвам итә торган геосәяси кризис, Россия гражданнарына, компанияләренә һәм банкларына карата халыкара санкцияләр саклану, нефтькә түбән бәя белән берлектә капиталның халыкара базарларында чикләүләрне көчәйтү, шулай ук күрсәтелгән факторлар тудырган икътисади хәлнең начараюы һәм Россия икътисадының түбәнәюе шартларында гамәлгә ашыру әлеге этапта Стратегияне гамәлгә ашыруда максатчан күрсәткечләргә җитмәү куркынычы белән бәйләнгән.

Икенче этап (2019 - 2021 еллар) конкурентлык сәләтен үстерү моделенә нигезләнә. Кластерлы активлашу кысаларында «заманча икътисадны» модернизацияләү тизләнәчәк һәм «акыллы икътисад»ның башлангычларын булдыру башланачак, регионара һәм халыкара интеграция проектлары старт алачак. Тышкы конъюнктура яхшырачак, үсеш темплары артачак.

Өченче этап (2022 - 2024 еллар) - кластерлы активлашу, яңа балансслы үсеш моделенә күчү, кеше потенциалы һәм социаль пространство сыйфатын сизелерлек яхшырту, «заманча икътисад»ның структур модернизациясен тирәнәйтү, яңа «акыллы» икътисадны шактый үстерү, инновацияләрне икътисади үсешнең әйдәүче факторына әйләндерү нигезендә район икътисадының һәм социаль сферасының конкурентлыкка сәләтенең сизелерлек үсешен тәэмин итәчәк.

Дүртенче этап (2025 - 2030 еллар һәм алга таба) - икътисадның конкурентлык сәләтен арттырачак, берничә төп юнәлеш кысаларында конкурентлык сәләтенә ирешү өчен шартлар тудырылачак.

## 7. АМР Стратегиясен гамәлгә ашыру механизмы

Стратегияне гамәлгә ашыруның уңышы шарты булып барлык район җәмәгатьчелегенең механизмнарны билгеләү, уртак гамәлләрнең эзлеклелеген эшләү, ресурсларны өстенлекле юнәлешләренә һәм проектларга туплау өлешендә килешенүен тәэмин итү тора. Район белән стратегик идарә итү системасы - Стратегияне гамәлгә ашыруның иң мөһим элементларының берсе.

Район белән стратегик идарә итү системасының төп принциплары:

Стратегия-2030ны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге барлык район бергәлегенең уртак тырышлыгына бәйле, шул ук вакытта муниципалитет бизнес-бергәлек, иҗтимагый оешмалар, сәяси партияләр, шәһәрнең актив халкы белән беррәттән тигез хокуклы катнашучыларның берсе булып тора;

Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары - Стратегияне гамәлгә ашыруны координацияләүче төп оештыру органы;

Стратегияне гамәлгә ашыруның төп механизмы - эшчәнлеген планлаштыруга максатчан якын килү һәм муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру аша стратегик максатларга ирешү;

Район бюджетының чикләнгән булуы шартларында өстенлекле программаларны һәм проектларны сайлап алу зарурлыгы кискен булып тора. Шул ук вакытта сайлап алына торган проектларның өстенлекле критерийларының берсе - аларны гамәлгә ашырудан мультипликатив эффект булырга тиеш (ягъни берничә максатка ирешү мөмкинлеге). Моннан тыш, һичшиксез, дәүләт-хосусый партнерлык принципларында төзелгән проектлар өстенлек итәчәк. Арча муниципаль районын үстерү стратегиясе үзгәрмәскә тиешле соңгы документ булып тормый, ул ирешелгән ситуация нигезендә өстенлекле юнәлешләрне үзгәртүгә кадәр даими яңартуны күздә тота. Шул ук вакытта стратегик максат үзгәрешсез калырга тиеш. Моннан тыш, Стратегияне гамәлгә ашыру процессында тәкъдим ителгән проектларда чагылыш тапмаган яңа максатлар туарга мөмкин. Стратегик планлаштыру тәҗрибәсе күрсәткәнчә, стратегик идарә циклы характерга ия һәм шартлы рәвештә -аналитик,

план, гамәлгә ашыру һәм контроль- дүрт состав өлешенә бүленә. Шул ук вакытта Стратегияне эшләү һәм гамәлгә ашыру процесслары аерылгысыз диярлек, алар бер-берсен тулыландыралар һәм дәвам итәләр. Стратегияне эшләү (яки актуальләштерү) вәзгыятьне һәм булган тенденцияләрне анализлаудан башланган кебек үк, аны гамәлгә ашыру да беренче адымнардан ук аналитик эш белән бергә барырга тиеш.

АМР стратегиясе АМР депутатлары советы тарафыннан раслана. Аны актуаль хәлдә тоту максатында, аның чаралары, күчмә планлаштыру ысулын кулланып, ел саен тулылана яки төзәтелә.

АМР стратегиясен гамәлгә ашыру өчен җаваплылык үзәге булып АМР БК икътисад бүлеге тора.

АМР БК каршында баланс комиссиясе төзелә, анда квартал саен җирлекләрнең социаль-икътисади үсеше планнарын тормышка ашыру мониторингы нәтиҗәләре карала һәм аларны төзәтү турында карарлар кабул ителә. Баланс комиссиясе составына АМР БК җитәкчесе, аның урынбасарлары, авыл җирлекләре башлыклары, бюджет барлыкка китерүче предприятиеләр җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм башка министрлыклар вәкилләре керә, фикер алышына торган проблемаларның актуальлегенә бәйле рәвештә.

Әлеге Стратегия АМР составына керүче җирлекләрне социаль-икътисади үстерү планнарын эшләүгә нигез булып тора. АМР стратегиясенең төп максатларыннан һәм бурычларыннан чыгып, авыл җирлекләрен социаль-икътисадый үстерү планнары эшләнде, шуңа күрә АМР стратегиясен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү АМР авыл җирлекләрен үстерү планнарын үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләп бертуктаусыз башкарылачак.

Үз чиратында, АМР авыл җирлекләрен үстерү планын актуаль хәлдә тоту максатыннан, аларның чаралары шулай ук тулылана яисә, шуыша торган планлаштыру ысулын кулланып, ел саен төзәтелә. АМР авыл җирлекләрен үстерү планнары һәм аларга үзгәрешләр АМР һәм ОИСЭЗда ачыктан-ачык фикер алышуга кертелә, шуннан соң авыл җирлекләре башлыклары тарафыннан раслана.

## 8. АМР Стратегиясен гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

АМР Стратегиясен гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге 2030 елга билгеләнгән максатчан индикаторларга ирешү дәрәҗәсе буенча бәяләнә:

- тулай территориаль продукты 2,5 мәртәбә үсә;
- хезмәт җитештерүчәнлеге 65% дәрәҗәсендә;
- АМРда хезмәт хакының 2,3 тапкырга арта;
- социаль өлкә хезмәтләре белән тәэмин ителеш норматив дәрәҗәдән ким булмаган дәрәҗәдә;

## 9. Арча муниципаль районында гамәлгә ашырыла торган һәм үсеш стратегиясендә кулланыла торган муниципаль программалар исемлеге

1. «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы;
2. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы;
3. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль максатчан программасы;
4. «2022-2024 елларга Арча муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасы;
5. «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» муниципаль максатчан программасы;
6. Торак фондын капиталь ремонтлау программасы (җирле бюджет акчалары исәбеннән);
7. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы;
8. «2022-2024 елларга Арча муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы;
9. «2022-2024 елларга Арча муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасы;
10. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында муниципаль юл эшләре программасы муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән - ел саен;
11. «2021-2023 елларда муниципаль районы территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш» муниципаль программасы;
12. «2021-2025 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасы.
13. «2021-2023 елларга Арча муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы.
14. 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча муниципаль программа;
15. «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкы арасында наркоманлыкны профилактикалау» программасы;

16. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы;
17. 2022 - 2024 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча озак сроклы максатчан программа;
18. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм су объектларында иминлекне тәэмин итү» муниципаль максатчан программа;
19. «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында авыл яшьләре» муниципаль программасы;
20. «2022-2025 елларга Арча муниципаль районының энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасы.

**Арча муниципаль районының 2030 елга кадәрге фараз күрсәткечләре**

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 2016 ел | 2018 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | Фараз | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2030 ел |
| Даими халык саны (уртача еллык) | мең кеше | 52,62 | 52,27 | 50,9 | 50,2 | 49,8 | 49,6 | 49,6 | 49,6 | 49,6 |
| Тулай территориаль продукт - барлыгы (гамәлдәге бәяләрдә) | млн сум | 10851 | 12325,6 | 13882,2 | 14325,6 | 17721,46 | 19769,03 | 21135,86 | 22510,11 | 26250,3 |
| Өстәлгән бәя - барлыгы (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 1178,1 | 1214,5 | 2184 | 1709,5 | 1903,5 | 2113,5 | 2219,2 | 2330,1 | 2855,8 |
| Тулай территориаль продуктта кече һәм урта бизнес өлеше | % | 36,8 | 37,1 | 37,3 | 37,3 | 37,5 | 37,8 | 38,0 | 38,3 | 39,9 |
| Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә инновацион продукция өлеше | % | 7,5 | 8,5 | 10,1 | 10,5 | 11 | 12 | 12,5 | 13,0 | 15,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җибәрелгән үзендә җитештерелгән товарлар, икътисади эшчәнлекнең чиста төрләре буенча (гамәлдәге бәяләрдә) үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн. сум | 1485,3 | 1512,6 | 1738,1 | 1848,5 | 3831,9 | 4831,9 | 5231,9 | 5720,2 | 6458 |
| Кече (микропредприятиеләрне дә кертеп) һәм урта предприятиеләр әйләнеше (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 6253 | 6743 | 7017,1 | 7396,0 | 7669,7 | 7861,4 | 8065,8 | 8275,5 | 8768,1 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме | млн. сум | 7892 | 8765 | 9869,8 | 8832,8 | 11287,8 | 12193,3 | 12960,4 | 13803,1 | 14598,3 |
| Финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән төп капиталга инвестицияләр күләме (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 2486,5 | 2896,8 | 3349,5 | 3657,1 | 4300,1 | 4500,6 | 4265,3 | 4425,3 | 5421 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ваклап сату әйләнеше (барлык сату каналларында) (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 2997,3 | 3369,3 | 3957,6 | 4522,8 | 5422,2 | 6082,8 | 6527,5 | 7005,7 | 8181,3 |
| халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 241,3 | 258,2 | 274,9 | 299,9 | 336,3 | 368,9 | 396,3 | 425,7 | 520,1 |
| Икътисадта мәшгульләр саны (уртача еллык) - барлыгы | мең кеше | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 |
| Хезмәт хакы фонды - барлыгы | млн. сум | 2171 | 2537 | 2779 | 3134,6 | 3534,2 | 3826,9 | 4135,0 | 4456,7 | 4828,2 |
| Предприятие һәм оешмалар хезмәткәрләренең уртача исемлек саны - барлыгы | кеше | 9112 | 9100 | 9110 | 8727 | 8740 | 8780 | 8817 | 8824 | 8800 |
| Бер хезмәткәрнең уртача айлык хезмәт хакы - барлыгы | рублей | 19852 | 23233 | 25423 | 29932 | 33698 | 36322 | 39081 | 42088 | 45722 |
| Бер кешегә акчалата керемнәр ( айга уртача) | рублей | 16370 | 17399 | 18879 | 20437 | 22277 | 23836 | 25481 | 27239 | 29591 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджетка салым һәм салым булмаган түләүләрне кертү - барлыгы | млн. сум | 397,9 | 446,7 | 499,1 | 252,9 | 539,1 | 555,3 | 565,3 | 568,1 | 618,1 |
| Физик затлар керемнәренә салым | млн. сум | 290,5 | 319,8 | 363,6 | 366,9 | 377,9 | 389,2 | 409,2 | 426,9, | 465,4 |
| Мәшгульлек хезмәтләрендә теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына) | кеше | 143 | 120 | 295 | 112 | 105 | 105 | 105 | 105 | 105 |
| Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе | % | 0,6 | 0,5 | 1,16 | 0,45 | 0,42 | 0,42 | 0,42 | 0,42 | 0,42 |

**2030 елга кадәр Арча муниципаль районы бюджетының керемнәре һәм чыгымнары фаразы (мең сумнарда)**

| Күрсәткеч исеме | 2023 | 2024 | 2025 | 2030 |
|---|---|---|---|---|
| **Җирле бюджет керемнәре** | **1 756 103,44** | **1 761 673,85** | **1 775 809,07** | **2 130 970,88** |
| 1. Салым керемнәре, шул исәптән | 546 661,0 | 580 047,5 | 624 587,0 | 749 504,4 |
| 1.1. Физик затлар керемнәренә салым | 443 848,0 | 474 768,5 | 516 746,0 | 620 095,2 |
| 1.2. эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым | | | | |
| 1.3.Патент | 13 864,0 | 14 419,0 | 14 996,0 | 17 995,2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.4. Гадиләштерелгән системаны куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 36 658,0 | 38 124,0 | 39 649,0 | 47 578,8 |
| 1.4. Бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 21.880,0 | 22.915,0 | 23.952,0 | 24.1 142,4 |
| 1.6. Физик затлар мөлкәтенә салым | 13 677,0 | 14 087,0 | 14 510,0 | 17 412,0 |
| 1.7. җир салымы | 32 923,0 | 32 923,0 | 32 923,0 | 39 507,6 |
| 1.8. Дәүләт пошлинасы | 4 210,0 | 4 210,0 | 4 210,0 | 5 052,0 |
| 1.9. Башкалар | 601,0 | 601,0 | 601,0 | 721,2 |
| 2. Салым булмаган керемнәр | 15 828,0 | 16 135,0 | 16 366,0 | 19 639,2 |
| 2.1. Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 9 574,0 | 9 764,0 | 9 864,0 | 11 836,8 |
| 2.2. Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 3 786,0 | 3 780,0 | 3 780,0 | 4 536,0 |
| 2.3. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 411,0 | 411,0 | 411,0 | 493,2 |
| 2.4. Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 2 057,0 | 2 180,0 | 2 311,0 | 2 773,2 |
| 2.5. Башка салым булмаган керемнәр | | | | |
| 3. Акцизлар | 38 200,0 | 37 700,0 | 39 000,0 | 46 800,0 |
| 4. Башка дәрәҗәдәге бюджетлардан кире кайтарылмый торган керемнәр, шул исәптән | 1 155 414,44 | 1 127 791,35 | 1 095 856,07 | 1 315 027,28 |
| - дотацияләр | 78,7 | 0,0 | 2 064,6 | 2 477,5 |
| - субвенцияләр | 501 933,44 | 505 635,7 | 506 758,97 | 608 110,76 |
| - субсидияләр | 653 402,3 | 622 155,7 | 587 032,5 | 704 439,0 |
| Башка керемнәр | | | | |
| авыл җирлекләре бюджетларына дәүләтнеке булмаган оешмалардан башка кире кайтарылмый торган кертемнәр | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан муниципаль районнар бюджетларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | | | | |
| - узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару | | | | |
| **Җирле бюджет чыгымнары** | **1 756 103,44** | **1 761 673,85** | **1 775 809,07** | **2 130 970,88** |
| 1. Гомумдәүләт мәсьәләләре | 102 783,0 | 103 551,15 | 106 675,57 | 128 010,68 |
| 2. Милли оборона | 2 970,9 | 3 110,9 | 3 225,3 | 3 870,4 |
| 3. Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 3 786,8 | 3 805,5 | 3 880,6 | 4 656,7 |
| 4. Милли икътисад | 88 217,8 | 86 988,9 | 86 528,80 | 103 834,56 |
| 5. Торак-коммуналь хуҗалык | 58 473,1 | 59 052,6 | 61 645,50 | 73 974,60 |
| 6. Әйләнә-тирә мохитне саклау | 1 012,0 | 1 012,0 | 1 012,00 | 1 214,40 |
| 7. Мәгариф | 1 196 941,7 | 1 201 560,0 | 1 208 193,90 | 1 449 832,68 |
| 8. Мәдәният, кинематография | 185 211,3 | 185 102,6 | 185 708,90 | 222 850,68 |
| 9. Сәламәтлек саклау | 903,9 | 939,2 | 976,70 | 1 172,04 |
| 10. Социаль сәясәт | 33 679,7 | 34 525,2 | 35 333,20 | 42 399,84 |
| 11.Физик культура һәм спорт | 82 123,2 | 82 025,8 | 82 628,60 | 99 154,32 |
| Профицит, кытлык (-) | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| | | | | |